Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

Иман

№ 4 (632) 27 февраль, 2017 ел (1438, Җөмәдел-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

Форум бүгенге көн сорауларына җавап бирде

14 февральдә Чаллының “Ак мәчете”ндә “Мөселман өммәте һәм бүгенге көн бурычлары” исеме астында мөселманнар форумы узды. Аның эшендә Кама аръягының 12 районыннан (Түбән Кама, Тукай, Актаныш, Әгерҗе, Мөслим, Минзәлә, Сарман, Мамадыш, Зәй, Меделеевск, Алабуга) имам-мөхтәсибләр һәм имамнар катнашты. Форум кысаларында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев белән очрашу да булды.

Иң башта форум эшендә катнашучылар “Ак мәчет” мәдрәсәсендәге Татар Ислам мәгарифе музее белән таныштылар, шушы темага видеотапшыру карадылар. Аннары нәзарәтнең зәкәт, хаҗ, хәләл стандарты комитетлары эшчәнлеге хакында мәгълүмат бирелде. Форумда катнашучыларны Чаллы мөхтәсибәте эшчәнлеге белән аның имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин таныштырды. Төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлинең чыгышы имамнарның бүгенге ролен күтәрүгә багышланды. Ә Түбән Кама районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин үзләрендә дини мәрәсимнәрне үтәү буенча тупланган эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Форумда катнашучыларны баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, Чаллы шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Мәрван улы Хәлимов сәламләделәр. Мөфти Камил хәзрәтнең чыгышы мәзһәбебез кыйммәтләрен аңлатуга багышланды. Ул шулай ук форумда катнашучылар сорауларына җаваплар бирде. Сораулар дәваханәләргә, балалар учреждениеләренә хәләл тулану кертү, зәкәт тәләү, хаҗ кылу буенча уку әсваплары белән тәэмин итү, авыллар өчен кадрлар әзерләү, имамнарның белемен күтәрү хакында иде. Камил хәзрәт чыгышының ахырында эшчәнлекләре дин белән бәйләнгән бер төркем хезмәткәрләргә нәзарәтнең Рәхмәт хатларын тапшырды. Мондый бүләккә Рамил Мәрван улы, шәһәр хакимиятенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге җитәкчесе Рөстәм Рәфыйк улы Галиуллин, “Ак мәчет” мәдрәсәсе мөгаллиме Габделмәлик хәзрәт Саттаров, шәһәрнең “Кәүсәр”, “Ихлас” мәчетләре имам-хатыйблары Фәрит хәзрәт Фатыйхов, Илназ хәзрәт Яхин лаек булдылар.

Форумда катнашучылар хөрмәтенә аш мәҗлесе уздырылды.

Форумда ясалган чыгышларның кайберләре белән газетабызның икенче битендә танышырга мөмкин.

Рәсемнәрдә: мөфти хәзрәт”Ак мәчет” мәдрәсәсе мөгаллиме Габделмәлик хәзрәт Саттаровка Рәхмәт хаты тапшыра; форумнан күренешләр.

“РАСЛЫЙМ”
ҮДО – ТҖМДН Рәисе,
Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин

Балаларның Республика күләмендә Чаллыда язгы каникуллар чорында үтә торган традицион Коръән уку бәйгесе шартлары

Бәйге ҮДО – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Чаллы шәһәре мөхтәсибәте призларына 22 нче ел үткәрелә. Оештыручылары – ҮДО – ТҖМДН, Чаллы мөхтәсибәте, “Ислам нуры” Дини-эшмәкәрлек Үзәге.

Үткәрелү вакыты: 22 март 2017 ел, иртәнге 9 сәгатьтә. Теркәлү анкеталар нигезендә иртәнге 7.30 сәгатьтән.

Үткәрелү урыны: Чаллы шәһәренең “Ак мәчет”е (Яңа шәһәр, 2/14, “Ак мәчет” туктальышы. Тел. (8552) 56-65-99 (Мөхтәсибәт); 38-67-02 – “Ак мәчет” имам-хатыйбы.

Бәйгедә 15 яшькә кадәрге, көндезге мәдрәсәләрдә укымаучы, Коръәнне тәҗвид илә яхшы укый белүче ир һәм кыз балалар катнаша. Ул 4 яшь төркемендә бара:

1. 7 яшькә кадәр.
2. 10 яшькә кадәр.
3. 13 яшькә кадәр.
4. 15 яшькә кадәр.

15 яшен тулганнар бәйгедә катнаштырылмый.

Бәйге малайлар һәм кызлар арасында аерым-аерым үткәрелә. Җиңүчеләр балл системасы нигезендә билгеләнә. Ул түбәндәге юнәлешләр буенча туплана:

1. Коръәнне тәҗвид илә карап уку: 0 – 12 балл.
2. Коръәнне тәҗвид илә яттан уку: 5 - 12 балл.
3. Мәкам: 1 – 3 балл.
4. Мөселманча киенеш, үз-үзеңне тотыш: 1 – 2 балл.

Җиңүчеләрне бүләкләү:

Һәр яшь төркемендә өчәр призлы урын билгеләнә. Җиңүчеләр истәлекле бүләкләр һәм дипломнар белән бүләкләнә. Кызлар һәм малайлар арасындагы иң яшь катнашучыларга шулай ук призлар бирелә.

Бәйгегә мөхтәсибәтләр, Чаллы мәчетләре үзләрендә уздырылучы Коръән бәйгеләрендә жиңүчеләрне юллыйлар. Вәкилләр саны һәр яшь төркемендә 2 кешедән артмаска тиеш. Күрше өлкә, республика вәкилләре бәйгедә башкалар белән тигез шартларда катнаша.

Бәйге шартлары 2017 елның 30 гыйнварында Чаллы шәһәре имамнары җыелышында кабул ителде.

VII Корылтай 17 апрельдә уздырыла

ТР МДНнең 16 февральдә узган чираттагы Пленумы утырышы шундый карар кабул итте. Пленум мөфти, баш казый һәм мөфтинең беренче урынбасарына кандидатларны раслады. Мәгълүм булганча, Диния нәзарәтенең 11 гыйнвар Пленумы карары нигезендә бу вазыйфаларга кандидатлар күрсәтү 13 гыйнвардан башлап 13 февральгә кадәр барды. Кандидатлар исемнәре мөхтәсибәтләр уздырган җыелышларда аталды.

Мөфтилеккә рәсми кандидат итеп Камил хәзрәт Сәмигуллин расланды (“Тынычлык” мәчете имам-хатыйбы, Татарстан мөфтие).

Баш казый вазыйфасына рәсми кандидат итеп Җәлил хәзрәт Фазлыев (Балтач районы имам-мөхтәсибе, баш казый), расланды.

Мөфти урынбасары вазыйфасына рәсми кандидат итеп Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин (Казанның Совет районы имам-мөхтәсибе, төньяк-көнбатыш төбәге казые), Илфар хәзрәт Хәсәнов (“Кол Шәриф” мәчете имам-хатыйбы) расланды.

ТР МДН тарихында беренче мәртәбә делегатлар санына чикләү куелмады, мөхтәсибәтләр Корылтайга күпме имам алып килүләрен үзләре билгеләде.

Камил хәзрәт: “Аллаһы Тәгалә безгә Әбү-Хәнифә мәзһәбендә булырга насыйп итте”

Барыбыз да таныйбыз: имам Шәфигый зур галим булган. Галим генә түгел, ул шигырьләр дә язган. Ул ике шигырендә Әбү Хәнифә турында сөйли, аны мактый. Бер шигыре шундый: шәһәрләр һәм анда булган һәр нәрсә мөселманнарның имамы Әбү Хәнифә, аның шәригать, фикх буенча хезмәтләре белән бизәкләнде, Забур битләрендәге аятьләр кебек. Аңа охшаш мәгърибтә дә, мәшрикътә дә, Куфада да юк. Һәм бу шигыренең ахырында ул әйтә: “Әбү Хәнифә фикерен кире кагучыларга ком бөртекләре санынча Аллаһның ләгънәте булсын!” Ягъни кем Әбү Хәнифә фикерләрен кабул итмәсә, бу кешегә ләгънәт булсын! дип әйтә имам Шәфигый рәхмәтуллаһи галәйһи.

Аллаһыга шөкер, Раббыбыз безгә шушы мәзһәбтә булырга насыйп итте. Яңа елда Сүриягә барып кайттык. Шунда галимнәр белән аралаштык. Алар сорый: “Сез мәзһәбегезне ничек тотасыз?” Аннан соң бер галим янына — Нуретдин Гайтер янына кердек. Ул ничә ай сөйләшми иде, авырый. Янында улы. Ул бездән сорый, аннары аның колагына ачыклап аңлата. Галим бездән: “Сез нинди мәзһәбтә?”- дип сорый. Без үзебезнең 100 % хәнәфиләр булуыбызны әйттек. Ул башын күтәрде дә: “Вәис!”- дип кычкырды. Аннан безнең белән сөйләшә башлады. Бөтен кешеләр аптырашта. Берничә ай сөйләшми иде.

Аннан соң алар сорый: “Сез бит хаҗда 100% Хәнәфи буенча гамәл кыла алмыйсыз?” Безнең мәзһәб буенча хаҗда өч фарыз, 23 важип бар. Без аларны үтәргә тырышабыз. Кайтканда беркемнең дә җәзасы булмый. Шулай гамәл кылмасак бер сарык чалырга туры киләчәк — җәза була. 23 важип булса да без аларны үтибез. Сүрия галимнәре дә гаҗәпләнеп: “Ничек булдыра аласыз?”- ди. Тырышабыз. Бу буш сүз генә түгел. Безнең хаҗыбыз иң камил рәвештә оештырылган.

Башка бер мисал китерәм: бер хәзрәт голәмәләр каршында башка бер хәзрәтне гаепләде: “Бу хәзрәт зина кылды,”- дип. Нишләп? “Икенче хатын алганда вәли булмаган, никахы дөрес түгел,”- дип әйтә. Тирмизидә китерелгән хәдискә таяна: “Әгәр дә бер хатын-кыз вәлинең рөхсәте булмыйча кияүгә чыксса, аның никахы батыл, ягъни дөрес түгел.” Бу хәдис сахих, сахих җыентыгында китерелгән. Без әйттек: “Ул бит Хәнәфи мәзһәбе буенча эшләде. Хәнәфи мәзһәбендә ул никах шартларына керми. “Ә теге кеше: “Мин Хәнәфи булсам да пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисе бар. Бу хәдис буенча без гамәл кылырга тиеш булабыз,”- ди. Әмма безнең мәзһәбебездә беренче чиратта аять тора. Аятьтән соң таватыр хәдис булса аңа игътибар итәбез. Әхәд хәдис булса, Әхәд хәдискә аять аша мәгънә бирәбез. Киресенчә түгел. Аллаһы Тәгалә “Бәкарә” сүрәсендә: “Әгәр дә өченче тапкыр хатыныңа талак бирсәң, бу ир кешегә бу хатын-кыз хәләл булмас, хәта ул икенче иргә кияүгә чыкканчыга кадә,”- диелә. Ягъни беркем бирми, ул үзе чыга, үзе ирекле. Аннан соң Гайшә анабыздан шундый хәдис килә: “Минем янымда ансарлардан бер кыз бар иде, мин аны кияүгә бирдем.” Ә хатын-кыз беркайчан да вәли була алмый. Вәлинең булуы никах шартларыннан тормый. Әлбәттә, вәли ул кирәк. Әтидән рөхсәт алуың бик мөһим. Ләкин вәлисез укылса да никах никах булып санала, зина кылдылар, дип әйтмибез. Аннан соң мәзһәбебездәге иң көчле дәлил ул шул, бу хәдис кемнән килә? Гайшә анабыздан. Гайшә анабыздан Урва, Урвадан Зухрига күчә. Ибн Җөрәех берчакны Зухридан бу хәдис турында сорый. Зухри: “Мин бу хәдисне китермәдем, аны белмим,”- ди. Әбү Хәнифә рәхмәтуллаһи галәйһи : “Бу чылбырдагы кеше әлеге хәдисне белмәгәч, ул берничек тә дәлил була алмый,”- дип әйтә. Бу хәдисне китерә торган кеше аны инкяр итсә бу хәдискә таянып булмый. Шундый хәдисләр бик күп. Мәсәлән: “Мәчет күршесендә намаз мәчеттә генә кабул була. “Әмма без барыбыз да беләбез: әгәр дә бер кеше өендә намаз укыса, аның намазы дөрес. Ләкин ул җәмәгать савапларыннан мәхрүм калды. Аның намазы юк дигән сүз — саваптан мәхрүм калды дигән сүз. Ә беренче мисалга карата шундый йомгак ясый алабыз: вәлисез укылган никах ул дөрес, әмма аныңда бәрәкәт юк.

Тәсбих мәсьәләсе. Безгә шундый сорау бирәләр: “Сез хәнәфиләр дөрес эшләмисез, тәсбихне фарыздан соң тартмыйча сөннәттән соң тартасыз, бу сөннәткә каршы килә. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) Бохарида китерелгән шундый хәдисе бар. Кыямәт көнендә ничек җавап бирерсез?” Әлбәттә, Бохари җыентыгындагы бу хәдисне без кабул итәбез. Ләкин Гайшә анабыздан килә торган икенче хәдис тә бар (Мөслим җыентыгы, 592 санлы). Мәрәкүл фәляһ китабында бу хәдискә ачыклык кертелә: “Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәлам биргәч сөннәт намазына баса.” Ягъни кулыбызда бу темага кагылышлы ике хәдис бар. Бер хәдистә пәйгамбәребезнең (с.г.в.) фарыздан соң тәсбих тартуы турында әйтелә. Икенчесендә - тәсбих тармыйча сөннәткә басуы хакында. Хәдис фәнендә шундый кагыйдә бар: бер темага кулыбызда ике сахих хәдис булса, без аларны берләштерергә тиеш булабыз. Һәм әйтәбез: беренче хәдис иртәнге һәм икенде намазлары хакында сөйли. Иртәнге һәм икенде намазларыннан соң без беренче хәдис буенча гамәл кылабыз. Икенче хәдис калган намазлар турында сөйли. Кыямәт көнендә бирерлек җавабыбыз бар: “Ий, Раббым, пәйгамбәребезнең ике хәдисе бар иде, без алар буенча гамәл кылдык,”- дип. Ә теге кешегә әйтәбез: “Ә син Кыямәт көнендә ничек җавап бирә аласың?”

Мәчеттә - дини мәрәсимнәр Үзәге

Халык керткән көчне без халыкка кайтарырга бурычлы. Әле аның табышы да булсын. Шуңа күрә шәһәрдә, авылда мәчет бар икән, аның халкы мәчетнең барлыгын белеп, тоеп, сизеп торсын. Әлбәттә, мәчет тырышырга, эшләргә тиеш. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Кешеләр арасында иң хәерлеләре — башка кешеләргә күбрәк файда китерә торганнары.” Бу безнең бик мөһим вазыйфабыз. Дини мәрәсимнәрне тиешле дәрәҗәдә, сыйфатлы итеп үтәү — ул шушы халыкка хезмәткә керә. Чөнки, әлхәмделилләһ, бүген безнең кулда зур көч. Кеше шатланса да, авыр вакытта да безгә килә. Бала туса да, балаларын никах юлына озатсалар да безгә киләләр. Авыр вакытта - әтисе, әнисе вафат булганда: “Хәзрәт, нишлик?”- дип мәетне юдырырга, җеназа укытырга киләләр. Беренче чиратта үзебезгә зур файда. Чөнки халыкның күңеле булса, аңа вәгазь-нәсихәт тә үтә. Хәзрәткә килгәч җитәкче дә тыңлый башын аска иеп, җеназада без хуҗа. Анда шәһәр башлыгы да түгел, башкалар да. Без алып барабыз, дога белән озатабыз. Менә бу әйберләргә без зур игътибар бирергә тиеш. Түбән Кама шәһәрендә мәчет зур, халык күп керә. Чөнки бездә мәчетләр, кызганычка каршы, күп түгел. Дини мәрсимнәрне үтәгәндә безгә бик күп нәрсә охшамый иде. Ни өчен? Мәсәлән, кеше телефоннан никах заказывать итә: “Менә безнең шимбә никах, җибәрегез безгә мулла.” Кемнәр алар? Аның кияүе кем? Әти-әниләре исән-саумы? Шаһитләре кем? Без бит инде янгынчылар төркеме түгел — янгын чыккан, срочно никах кирәк. Бу бит никахның дәрәҗәсен төшерү була. Менә шушы тормыш вакыйгалары безне никах мәсьәләсен шактый гына катлауландырырга мәҗбүр итте. Шәһәрдә гариза бирергә ЗАГСка барсаң, сиңа әйтәләр: “Барыгыз, берәр ай уйлап килегез әле. Бәлки уйлап бетермәгәнсездер,”- дип. Аксакаллар, остазлар белән җыелып киңәшләштек тә, никахлашучыларга шартлар куйдык. Беренчедән, заявкаларны телефоннан алмый башладык. Килсеннәр, күреп сөйләшик. Икенче этап — гаризаларны ала башлагач атнага ике дәрес куйдык. Коллектив зур булгач мондый мөмкинлек бар. Гариза язган пар никахка кадәр кимендә бер дәрестә катнашырга тиеш. Бу никах дәресе дип атала. Яшьләр башта зарландылар, аннан соң, шулай кирәк, дип килә башладылар. Һәм менә остазлар яшьләр белән утыра. Алар бернәрсә белмиләр. Ничек безнең талаклар күп булмасын. Гаилә, никах турында егет тә, кыз да белми. Менә бу әйберләрне аңлату бик файдалы. Без дәресләрдә мәҗлес турында да аңлатабыз. Хатын-кызлар утыра икән, алар яулыктан, озын җиңле күлмәктән булырга тиеш. Нинди ризык? Боларны телефон аша заявка алып контрольдә тотып булмый. Ә монда килгәч без аңлатабыз табыныңда шул булырга тиеш, хәләл ит кирәк булса — менә аның адресы дип. Кеше белән күрешеп эшләүнең файдасы бик зур. Никах журналы тутырылып бара — кем әңгәмә үткәргән. Никахта берәр проблема килеп туса — без шундук ачыклыйбыз — кем әңгәмә үткәргән, нигә ул мәсьәлә хәл ителмәгән? Үзебез моннан бик зур файда күрәбез.

Һәм тагын бер катлаулы як — үлем-китем, җеназа мәсьәләсе. Чөнки монда без тиешле дәрәҗәдә аларга ярдәм итә алсак, әлбәттә, иман да аның күңеленә кереп калачак. Чөнки син аның әтисен озаттың, әнисен озаттың. Һәм ул аңа мәчеткә йөрү өчен беренче адым була.

Вафат булучыларны соңгы юлга озатканда еш кына авырлыклар килеп туа иде. Чөнки көнгә унга якын мәет була, 20-30 градус салкында чыгып китәргә кирәк. Без бик күп кенә уйлап-фикерләшкәннән соң шундый карарга килдек: җеназаханә төзәргә. Цивилизацияле илләрдә - гарәп, төрек илләрендә бу әйберләр бар. Хаҗга баргач үзебез күреп кайттык. Һәм без җеназаханә бинасын эшләдек. Ул безнең 5 йолдызлы булмаса да, 3 йолдызлы отельдән ким түгел. Һәм бу минем тәҗрибәмдә әҗәтсез эшләнгән бердәнбер объект булды. Мәчет салсаң еллар буе әҗәт түләп йөрисең. Без бер мәчет төзедек — 12 суд булды инде. Ә монда хәтта безнең автомашинага акча калды. Яхшы ак машина алдык. Кешеләр бу проектны шул кадәр яратып кабул итте, хәтта урыс җитәкчеләре: “Менә минем оешмада кеше постоянно үлә, нишләтергә, ничек ярдәм итәргә белми идем, мин дә акча бирим,”- дип ярдәм күрсәттеләр.

Бабайлар әкрен генә шулай яңача эшли башладылар. Үлем-җитем булса, бабайлар әйтәләр: “Кирәк булса өегезгә җибәрәбез, кирәк булса безгә алып киләсез.” Кеше җеназаханәне сайлый башлады. Беренче шикләнә, мин өйдән алып китәм, ди. Барып күргәч фикере үзгәрә. Җеназаханә бинасы заманча шифаханә кебек: аның көтә, утыра торган җирләре, аерым суыту камерасы бар. Җеназаханә мәчет ишек алдында да булгач, кеше күңеленә ята. Узган елны гына 652 мәрхүм белән мөрәҗәгать иткәннәр, шуның 603 җеназаханәне сайлаган.

Никах, җеназа мәсьәләләрен, исем кушу, Коръән уку, искә алу мәҗлесләрен бер тәртиптә тоту өчен без, Аксакаллар белән киңәшләшеп, мәчеттә дини мәрәсимнәр Үзәге төзедек. Ул хәзер мәчетнең бер бүлеге кебек. Бер бабайны без шунда җитәкче итеп куйдык. Ниндидер ризасызлыклар булганда бабайлар җыелып бу мәсьәләне үзләре хәл итә. Үзәкнең булуы шушы эшләрне җайга салырга ярдәм итте. Һәм, әлбәттә, имамнар да, мөхтәсиб тә шушы тәртипкә буйсына. Миңа кемдер килә икән, әйдә әле, хәзрәт, кызыма никах укы, дип, мин әйтәм: “Сез шунда барып язылыгыз. Балаларыгыз дәресне кабул иткәннән соң: “Йосыф хәзрәт белән сөйләшкән идек, ул бара,”- дип әйтегез,”- дим. Имам-мөхтәсиб тә бу әйбергә буйсынырга тиеш була.

Авылларда, әлбәттә, җеназаханә төзеп булмый. Әмма җеназаны, башка эшләрне җиңеләйтү өстендә күп эшләргә мөмкин. Әйтик, һәрбер мәчеттә мәет чемоданы бар. Аның берсе ирләр, икенчесе хатын-кызлар өчен. Без Үзәк мәчеттә 7-8 ел элек бу әйберләрдән киттек. Ягъни чемоданнарны чыгарып аттык. Ни өчен? Чөнки ул зур проблемалар тудыра. Кешегә аны килеп алырга кирәк, аннан соң бабайлар андагы халатларны кияләр. Бабайлар халатларны салып калдыргач

хуҗалар аларны юарга тиеш. Ярый, авылда аны мунчада юып коймага эләргә була. Ә шәһәрдә кайда юасың аны? Киемең белән бергә юасыңмы? Аңа ис сеңеп бетә. Әле ул кибеп бетми, аны үтүкләмиләр — киптереп бетермиләр. Ул бурсый. Мәет юарга килгән бабайлар зарлана. Шуңа күрә без уйладык та, шифаханәләрдә хирурглар тарафыннан операция ясаганда куллана торган халатлар алдык. Интернеттан заказать иттек — ярты вагон. Хәтта башка районнарга да җитәрлек. Халык рәхмәтен әйтеп туялмый — соңыннан халат юып йөрисе юк. Реклама дип уйламагыз, аны башкалар да сата. Аерым пакетлар ясадык. Аңа өч халат салдык, аларның алды ламинированный, юучы әбинең, бабайның күлмәгенә су үтмәсен өчен. Башлыгын да керттек, ис кермәсен өчен маскасы, перчаткалары бар. Чөнки кул белән юу дөрес түгел. Өч пар бахилы бар, фатирны пычратмаска. Һәм үзенең сабыны, губкасы бар, матур, чиста итеп юарга. Кешедән бернәрсә дә кирәкми. Киләләр. Алдан халатны киеп икенчесе бәйли. Соңыннан алып пакетка салып (әле аның чүп өчен пакеты да бар), тарттырып бәйләп китәләр. Кешеләргә бернинди мәшәкать калмый. Менә моны кешеләр үзләре сатып ала, үзләре безгә рәхмәт укый. Әле бер-икә сум өстәсәгез мәчеткә дә файдасы кала. Шундый элементар, җиңел әйберләрне без кулланмыйбыз. Мәчет исәбенә алып куйсаң да унны — ул 3,5 мең сум була - авыл өчен бер елга җитә.

Менә күп авылларда колаша проблема. Алар ватык була. Ярый, бабайлар карап, ямап тора. Кайбер авылларда һаман кабыкта юалар. Ул ярылып беткән була. Агачтан булуы да дөрес түгел. Анда микроблар кала, аларны юып бетереп булмый. Мөхтәрәм җәмәгать, бу бит проблема түгел. Без колашаларны азык-төлек өчен кулланылучы нержавейкадан эшләттек, аяклары җыела торган. Җип-җиңел, бер кулга гына күтәрәсең. Аның суы агып китәр җирләре бар. Үзебезгә генә түгел, тагын берничә районга эшләттек. Мәеткә сөенеп ятырга була. Аны авылга алсаң 20 елга җитә. Әтисен, әнисен җирләгәннән соң берәр хәллерәк кешегә әйтсәң, ул аны садака итеп алып бирә.

Көчебездән килгәнчә эшебезне сыйфатлы эшлик һәм халыкка катлаулы тормышны әз генә булса да җиңеләйтергә тырышыйк. Әгәр дә безнең халыкка хезмәтебез булса, әлхәмделилләһ, халык та килә, мәчетеңне дә карый, ремонтка да, газыңа түләргә дә, хезмәт хакына да акчаң була.

Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН.

Аксакал сүзе

Хөрмәтле Бөек Ватан сугышы чорында һәм аннан соңгы елларда туган илебезне аякка бастыру өчен үзегезнең фидакарь хезмәтләрегезне кызганмаган, көнне төнгә ялгап, тир түгеп басу-кырларда, фермаларда, төзелештә, завод-фабрикаларда эшләп ялга чыккан ветераннар! Минем сезгә әйтер сүзем бар.

Әссәләмү галәйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәрәкәтүһ!

Сезгә иман байлыгы, хәерле-бәрәкәтле гомер, сәламәтлек, яшъ буынны тәрбияләү өлкәсендә уңышлар, бәхет-сәгадәт теләп калам. Күп еллар буе башымда йөрткән үйларымны сезгә җиткерергә булдым әле. Без бит һәммәбез дә бер чорда, бер җирдә туып-үстек, бер җирнең суларын эчтек, үзебезнең басуларда үскән икмәкне ашадык, бер һаваны суладык. Сез минем күңелемә бик якын кешеләр. Мин бары тик сезнең фани дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле булуыгызны гына телим. Бүгенгесе көндә Европа халкының аңы уяна башлаганын һәм аларның Исламга килгәннәрен ишетәсез һәм күрәсез дип уйлыйм. Массакүләм мәгълүмат чаралары бик оператив эшли бит. Әйтегез әле ни өчен алар Исламга киләләр? Әле бит белүебезчә кайберәүләр Ислам динен һәм мәселманнарны еш кына яманлап, тәнкыйтьләп торалар. Ләкин, шулай булуына карамастан, дөньядагы халыклар сәгать саен, көн саен Исламга киләләр, Әлхәмдүлилләһ. Ни өчен халык Ислам диненә төркем-төркем булып килә башлады? Беренчедән, бу аларга Аллаһның рәхмәте. Икенчедән, халыкның аң-белеме үскәннән үсә бара, субхәнАллаһ. Алар Аллаһ кушкан җирләргә карап уйлый һәм фикерли башладылар. Алар үз-үзләренә ошбу сорауларны бирәләр:

— Галәмнәр кайдан, ничек барлыкка килгән?

— Дөнья ничек барлыкка килгән?

— Безне бу дөньяга кем китергән?

— Без ни өчен бу дөньяда яшибез?

— Бу тормыштан соң ни була?

Ошбу сорауларга үзләре үк җавап та эзлиләр. Җавапны Коръәннән, Ислам дине турында язылган китаплардан табалар. Чөнки Коръәндә һәм сөннәттә — Пәйгамбәребез саләллаһу галәйһи вәсәлләмнең хәдис-шәрифләрендә ачык итеп аңлатылган. Аңлы халык, аларны укып, Исламга килә. Ислам дине ул кешене канәгатьләндерә торган дин, бик күркәм дин. Ислам диненең гүзәллегенә карап таң калалар. Ислам тынычлык дине. Ислам иминлек дине.

Кызганыч ки, Татарстанда, Рәсәйдә Исламга килүчеләр саны азрак. Ни өчен дисезме?

— Беренчедән, безнең илдә халык уйларга, фикерләргә гадәтләнмәгән. Күпчелек кеше ашый-эчә, йоклый, эшли, хаҗәтләрен үти, һәм бернәрсә дә уйламый.

— Икенчедән, безнең илдә халыкның күпчелеге исерткеч белән мавыга. Исерткеч кешенең уйлау сәләтен киметә, зиһененә зыян сала.

— Өченчедән, Рәсәй халкы җитмеш ел дәһрилектә-динсезлек сәременә батып яшәде. Бу чорда меңнәргә гыйбадәтханәләр җимерелде, дин әһелләре үтерелде, юк ителде. Динле кешеләрнең күбесе эзәрлекләүләргә, репрессияләргә дучар ителде. Бу кадәр басымга түзә алмыйча үз иманнарын, ата-баба иманнарын компартия уйлап чыгарган ялган инануларга алмаштыручылар да булды. Коръән һәм хәдисләр теле онытылды, намазга басучылар саны кимеде.

— Дүртенчедән, кайберәүләр: “Мин хәзер теләсәм, теләмәсәм дә динне кабул итә алмаячакмын, мин картайдым, вакыт үтте,”- дигән фикерне алга сөрә. Шул рәвешле үзенең ялкаулыгын, дәһрилеген (наданлыгын) акларга маташа.

— Бишенчедән, бәндәләрнең күпчелегә Аллаһның сүзен тыңлый белми, ишетсә дә ул аны аңламый, Раббысының сүзендәге матурлыкны күрми дә, сизми дә. Шуның өчен ул аны кабул да итә алмый.

— Алтынчыдан, кемнәрдер аны дингә якын килмәслек итеп нәфрәтләндергәннәр. “Дин ул — опиум” дигән ялган уйдырманы башына сеңдергәннәр. “Дин — ул кешегә зарар китерүче” дип алдалаганнар, ялган фикер белән зиһенен томалаганнар. Надан кеше ул ялганга ышанып Ислам диненә нәфрәтләнә, аны кабул итми.

— Җиденчедән, ул дингә килергә курка. Ул — “Әгәр дә дингә килсәм дөнья ләззәтләреннән мәхрүм булачакмын,”— дип уйлый.

Безнең көннәрдә үзләрен мәселман дип атап йөрткән милләттәшләребез арасында киң таралган бер күренеш бар: намазның, елга бер ай ураза тотуның фарызлыгын таныйлар, әмма үзләре бу гыйбадәтне үтәмиләр. Кешеләр гөнаһлы ләззәт төшенчәсе белән чын бәхет-сәгадәтне бутый. Бугенге көндә аларның урыннары алмашынган. Андый кеше теоретик яктан Ислам кануннарыннан яхшы хәбәрдар: исерткеч эчү, тәмәке тарту, фәхеш эшләр динебез тарафыннан тыелган икәнне яхшы аңласа да, яшәвенең бөтен мәгънәсе нәкъ менә шуларга корылган. Чөнки дингә килсә, боларның һәммәсеннән дә баш тартырга һәм әйләнә — тирәдәгеләр өчен мәңге үрнәк булып яшәргә туры киләчәк, ә бу исә зур җаваплылык. Менә шунысы куркыта адәм баласын.

Шулай ук түбәндәге хакыйкатьне дә истә тоту мөһим: бары тик дини кануннар үтәүнең зарурлыгын аңлау белән чикләнмичә, шуларны үтәүдән җанга, күңелгә ләззәт алу турында онытмасак иде, моның әһәмияте искиткеч зур!

Исламның биш терәге — шәһәдәт кәлимәсен әйтү, намаз, ураза, зәкәт, хаҗ — боларны үтәп яшәү хакыйкиятүл иман дип атала. Бар тагын халәвәтүл иман дигән төшенчә. Монысы әнә шул гыйбадәтләрне кылудан җан рәхәте кичерүгә кайтып кала, моның исә мәгънәсе күпкә киң. Кешене куркытып иманга китереп булмый, ә менә мәхәббәт, изге ярату күп нәрсә бирә. Аллаһны яраткан өчен генә шул кешегә карата олы ихтирам, хөрмәт саклавыбыз Аллаһ хакын үтәүгә тиң. Дини гыйбадәтләрне үтәргә Раббыбыз тарафыннан вакыт бүлеп куелган. Кеше шул кыйммәтле вакытын тиешле кулланмаганда, юк-барга сарыф иткәндә, әлбәттә, игелекле гамәл кылырга каян җиткерә алсын ди вакытны!

“Намаз укырга вакытым юк” дип әйтү ул дини гыйбадәтне үтисе килмәүне яшерергә тырышудан башка нәрсә түгел!

“Әзерлегем җиткәч йөрермен мәчеткә” дип акланучыларга бер сорау куясым килә: мәчеттән дә ары, җәмәгатьтән аерылып, кайда әзерләнмәкче буласың? Бу кеше, әйтик, гаиләсендә, дус — ишләре, туганнары арасында да Ислам турында берни ишетми, белми, күрми, уйланмый, бу турыда аңлатучы, сөйләүче юк. Моның әзерлеге нинди шартларда үтә, гомумән бармы соң! Мәчет, җәмәгать — рухи азык чыганагы, без анда үз асылыбызны табар, аңлар өчен йөрергә тиеш. Шушы хакыйкатькә каршы кылу — эчке аңның иманга кайтырга теләмәвенә дәлил. Әгәр кеше чынлап та иманга кайтырга тели икән, биш вакыт намазын торгызырга тиеш. Әгәр инде гыйбадәтен кылмый икән, андый кешенең хәрамга кереп чумуы бик тиз. Чөнки Раббыбыз Үзе вәгьдә итә: “Мине онытканнарга дөньяның бөтен ишекләрен дә ачып куйдым,” — ди. Үз теләгең белән хәрамны сайлыйсың икән — рәхим ит, Раббың сине бернәрсәгә дә мәҗбүриләми. Болардан баш тарта алган кешегә генә Аллаһ Тәгалә рәхмәт капкаларын ача.

Адәм баласының психологиясе шундый — үзенә начар булганда гына Раббысын исенә төшерә ул. Кем өчендер каты авыру, юл һәлакатенә юлыгу. Ә теләк һәммәбезнең бер — “Раббым коткар мине бу бәлаләрдән!” дип ялварабыз. Кызганыч, шушы мизгелне бик азлар гына хәтерендә саклый, күбебез, хәлләр рәтләнеп китүгә үк, Аллаһны онытабыз. Җир йөзендәге яшәү шартлары инсаннарның михнәт күрмичә тормыш итүе өчен җайлаштырылган. Әмма без, шуларны күрә, белә торып та Аллаһка сәҗдә кылырга ашыкмыйбыз. Югыйсә, Аллаһ безнең намазларыбызга мохтаҗ түгел, бу гыйбадәт кешенең үзенә кирәк. Без үзебез чиксез Хикмәт иясе, барнәрсәне дә Белүче, Бөек, Бай, Кодрәтле, Җиңүче, Гафу итүче, Рәхимле Аллаһка мохтаҗ. Шуңа да, без — мәселманнар намазның һәр рәкагатендә “Фатиха” сүрәсен укыйбыз:

اياك نعبد و اياك نستعين

“Сиңа гына гыйбәдәт кылабыз, Синнән генә ярдәм сорыйбыз!”

Кадерле яшьтәшләрем, чордашларым! Аллаһка гыйбадәт кылуны калдырудан сакланыйк. Тормышта нинди генә хәлләрдә булсак та, фәкыйрьлектә яисә байлыкта, көенечтә яисә сөенечтә, көчле яисә зәгыйфь чагында Аллаһны исебездә тотыйк! Әле бит соң түгел, гүр иясе булмаганбыз. Һәрберебезгә тәүбә ишекләре ачык. Аллаһка ялварып, тәүбә — истигъфар кылыйк. Укылмаган намазлар, тотылмаган уразалар, бирелмәгән садакалар, чалынмаган корбаннар, түләнмәгән зәкәтләр һәм башка хаталар өчен елый-елый тәүбә — истигъфар кылыйк! Аннары, күңелебез, рухыбыз — җаныбыз пакъланганын сизәрбез, ин шәә Аллаһ! Аллаһның рәхмәте белән Аллаһка гыйбадәт кылырга күңелебез ашкынып торыр.

Һәммәбезнең дә Раббыбыз Аллаһ белән очрашү көне, очрашу урыны бар. Очрашу көне — кыямәт, очрашу урыны — мәхшәр мәйданы. Кыямәт көнендә барыбыз да каберләребездән кубарылып чыгарбыз һәм мәхшәр мәйданына җыелырбыз. Һәрберебезгә дә ул көндә Раббыбыз белән очрашырга туры киләчәк. Аллаһ синнән дөньяда яшәгәндә кылган гамәлләреңнән сорау алачак. Син Аллаһ белән очрашырга әзерме? Бу фани дөньяда яшәгәндә Аллаһка буйсынмыйча, Аның әмерләрен үтәмичә, гөнаһлар кылып яшәгән булсаң, Аллаһ Тәгалә ачуланып сине җәһәннәмгә салырга да Кадир. Аллаһка гыйбадәт кылып, изгелек эшләп яшәгән булсаң, Аллаһ Үзенең рәхмәте белән җәннәткә кертер, һәм син анда — җәннәттә мәңге рәхәттә калырсың. Уйларга, фикерләргә нигез бар: кайсы юлны сайлыйбыз?

Аллаһ ярдәме белән, Аллаһ илһам биреп сезгә дөрес юлны күрсәттем сыман, әлхәмдүлилләһ. Һәрберебезгә дә һидаятьтә — туры юлда булырга язсын!

Хөрмәт белән,

Чаллы шәһәренең Сидоровка бистәсе “Ихлас” мәчете аксакаллары рәисе Минсабир Таһир улы Вәлиев.

Хаҗия язмалары

Хаҗга – автомашинада

(Ахыры. Башы газетабызның № 2 (630) санында.)

Бүлмәләрдә бернәрсә юк — матрац, мендәр. Өскә ябынырга бернәрсә юк - конденционерлар эшләп тора, өшетә. Өскә намазлыкларны ябынып ята идек. Бүлмәдә безнең белән кытайлар, таджиклар, Казахстаннан, Кыргызстаннан килүчеләр. Чирли башладык. Дарулар да машинада онытылып калган. Ярый, Кытайдан килгән хатыннар бер-ике дару бирделәр дә, әзерәк җиңеләйдем. Ихрамга кереп Минага киттек. Анда палаткада яңадан чирли башладым. Бу үзенә күрә Аллаһы Тәгаләнең бер сынауы булды инде минем өчен. Гөнаһлардан арынырга сәбәп булсын. Нинди генә авыр булмасын Раббым миңа хаҗ гамәлләрен барсын да үтәп кайтырга көч-куәт бирде, әлхәмделилләһ!

Автор җәмәгате Рифкать хаҗи белән 1 декабрь, 2008 ел , ихрамга кергәч Төркия аэропортында;

Хаҗ бетүгә юлга кузгалдык. Гарәфә тавы яныннан үтеп киткәндә андагы җиргә ташланган чүпне күреп исем-акылым китте. Шундый изге җирдә кулыңдагы чүпне чүплеккә ташламыйча җиргә бәреп калдырганнарына бик тә гаҗәпләндем. Чүплек савытлары адым саен, эзләп тә йөрисе юк. Чүп кенә түгел, ашап бетермәгән ризыклар аяк астында. Болар өчен җавап бирәсе дә бар бит.

Кайтышлый Мәдинәгә кердек. Без үзебез белән алган ризыкларның күбесен Мәдинәдә шәкертләрдә калдырган идек. Шулар артыннан кергән идек. Алар әле хаҗдан кайтмаган иделәр. Без инде аларны көтеп торырга булмадык. Аллаһы Тәгаләгә тапшырып юлга кузгалдык. Гыйрак чигенә килеп җиттек. Анда безне дагыстанлылар каршы алды. Алар хаҗга бара алмаганнар — Гыйракта документларын урлаганнар. Документсыз границадан үткәрмиләр. Менә насыйп булмаса бер нәрсә дә эшләп булмый. Документлар кайчан була, әле аннан соң визаларны яптырып кире кайтырга диделәр — елап калдылар.

Иранда бер КамАЗ машинасы тау астына төшкән, кешеләре үлгән иде. Шулай ук дагыстанлылар. Инде кайтканда барган юл белән түгел, Әзәрбайҗан аркылы кайтырга булдык. Иран белән Әзәрбайҗан чигендә төн кундык. Әзербайҗанның ниндидер бәйрәме диделәр, кешеләрне кертмәделәр. Шунда безнең ризыклардан макарон да суган калган иде. Макарон пешердек тә, суын түгәргә җыенганда ир-атлар: “Суын түкмә, шулпасы белән ашыйбыз,”- диделәр. Шуның өстенә суган турап ашадылар. Мин: “Сезгә өйдә шулай пешереп бирсәң берегез дә ашамас идегез әле,”- дидем. Монда ашамыйча килгәч нәрсә дә бара икән. Шунда Әмир абый: “Машинаның утын сүндерегез, ату күрәләр безнең нәрсә ашаганны,”- дип көлдерде.

Волгоградка хәтле әйбәт кенә кайттык. Волгоградта безне гаишниклар туктатты, документларны тикшерә башладылар. Берсенә безнең паспортлар ошамады: “Загранпаспортлар шариковый ручка белән язылырга тиеш түгел,”- ди. Күпме илне барып әйләнеп кайттык — бер җирдә дә сүз әйтүче булмады. Боларга бәйләнергә бер сәбәп кирәк булды. Аннан соң каядыр шалтыратты да — безне җибәрделәр. Шулай итеп без исән-имин 7 көндә өйгә кайттыпҗиттек, әлхәмделилләһ. Иптәшемә тәмәкедән арынырга насыйп итте Раббым.

Аллаһы Тәгаләнең кушканнарының тагын бер баганасын үтәп кайткач яшәүләр бөтенләй үзгәрде. Анда барып, күреп, гамәл кылып кайткач кына барсын да аңлыйсын икән. Мин генә түгел, хаҗ кылып кайтучылар барсы да шулай ди. Аннан кайтканнан соң шушы елны ук иптәшем миңа: “Эшеңнән тукта, әнине карарга кирәк,”- дип әйткәч, мин эшемне ташладым да, авылга кайтып әнине карый башладым. Әнине караган арада авылдагы әбиләрне, картларны Коръән укырга өйрәттем. Шушы арада — 2003 елда, 2005 елда, 2008 елда хаҗга бардык. Әни мәрхүмәне 2011 елда җирләдек. Һәм аның өчен иптәшем, ә мин үземнең әнием өчен хаҗ кылдык. Ул елны үзебез белән үземнең апама да хаҗ кылырга насыйп булды. Кайтып китәр алдыннан саубуллашу тәвафы үтәгәндә апам: “Әй, сеңелем, монда тагын килергә насыйп насыйп булыр микән?”- ди. Минем шунда исем китте: “Әле сине үгетләп кенә алып килдек, тагын киләсең килә мени?”- дидем. “Әй, сеңелем, монда килгәч кенә беләсең икән,”- диде. Әлхәмделилләһ, 2011 елдан соң 3 тапкыр Гомрәгә бардык. Апам да бездән калмады. Рамазан аенда Гомрә үтәү пәйгамбәребез (с.г.в.) белән хаҗ кылган әҗер-савапка тиң икән.Шуңа күрә Гомрәгә Рамазан аенда баруың хәерлерәк. Без Аяз хәзрәт белән бардык, безгә бик ошады. Икә мәртәбә гомрә - кече хаҗ кылдык бер баруда. Мәдинәгә барып 3 көн торабыз да, яңадан ихрамга кереп кем өчен булса да гомрә кыла аласың. Аннан соң да Мәккәдә бер атна торып кайту юлына чыктык. Ашатулар программада булмаса да һәр көнне кайнар ризыклар китереп тордылар, Коръәннәр бүләк иттеләр. Кунакханәдән автобуслар 10-15 минут саен йөреп торды. Шул хәтле оешкан иде, Аллаһының рәхмәте яусын Аяз хәзрәткә һәм булышучыларына. Тагын барырга насыйп булса Аяз хәзрәт белән генә барырга ниятлибез, Аллаһ боерса.

Менә инде былтыр 6 нчы тапкыр хаҗга барырга насыйп булды. “Хаҗ Фонд” белән бардык: Казаннан Мәскәүгә, Мәскәүдән Дубайга, аннан соң автобус белән Мәдинәгә. Мәдинәдә булганнан соң ихрамга кереп Мәккәгә киттек. Җитәкчебез Мәлик хәзрәт иде. Юлларда тотрыксызлык булмады, барганда да, кайтканда да. Хаҗ гамәлләрен үтәгәндә тагын да җиңел булды. Минага 49 санлы автобуслар илтте. Шук ук автобуслар Гарәфәгә, аннан Мөздәлифәгә, аннан Минага алып барды. Бер җирдә дә җәяү йөрмәдек. Автобуслар берәзлексез ташып торды. Олы шайтанга таш аткач ир-атлар Мәккәгә таваф кылырга киттеләр. Без, хатын-кызларга, хәзрәт тәшрик көненең ахыргы көнендә генә кайтып тәваф кылырсыз диде. Ир-атлар таваф кылып кич сәг. 11 дә генә кайттылар Минага. Тәшрикнең 3 нче көнендә автобусларга утырып кунакханәгә кайттык һәм таваф кылып ихрамнан чыктык.

Үткән хаҗ бик җиңел булды, әлхәмделилләһ. Юлда булганда, бигерәк тә хаҗ гамәлен үтәү нияте белән юлга чыккач, юлдашчы һәм бүлмәдәш иптәшләреңнең нинди булуы мөһим. Аллаһыга шөкер, күпме барырга туры килде һәм хәерле бәндәләрне юлдашчы, бүлмәдәшче итте Раббым. Мең-мең шөкер, кабул гамәлләрдән булсын! Җитәкчеләргә Аллаһ ярдәм бирсен, һәрбер кешегә ярап бетәргә дә кирәк. Бигерәк тә картаеп дингә килгән кешеләрнең калебләрен турайтырга бик авыр. Шулай да кая барганыңны уйлап, тешеңне кысып булса да сабыр итәргә кирәк. Чөнки үзеңнең гамәлеңне дә, кешенекен дә юкка чыгаруың бар. Хәтта бер хаҗда булганда әбиеңнәр имамны елаттылар. Менә шунда инде минем исем китте. Шуңа күрә иманарга-җитәкчеләргә Аллаһ ярдәм бирсен.

Картайганчы ничек булса да барырга тырышырга кирәк хаҗ гамәлләрен үтәү өчен. Чөнки алдагыны белеп булмый, исәнлек ничек була. Аннары картайгач гамәл кылырга авыр, менә үземнән чыгып әйтәм. Яшерәк вакыттагы йөрүләр белән хәзерге йөрүләр бер түгел. Хатын-кыз юлга чыкканда үзе генә юлга чыкмасын иде, бигерәк тә картлар. Чөнки юл җиңел түгел, хаҗ гамәлен үтәве дә җиңел түгел. Һәр кеше үзенең гамәлен үзе үтәргә тиеш. Кеше өстенә салынып бетеп булмый. Раббым сезләргә дә хаҗ гамәлләрен үтәргә насыйп итсен һәм кылган гамәлләребез риядан булмасын иде. Шуларны Аллаһы Тәгаләдән сорап догада булучы,

Тәнзилә хаҗия Гыйрфанова,
Чаллы шәһәре.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР

Баш мөхәррире
Хәлил ШӘРИФ

Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
e-mail: islamnury@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы 1100.

Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, таныш-танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:

423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
27 февраль 16 сәг.,
фактта 27 февраль 16 сәг.

Бәясе ирекле